**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЮТАЗЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**423962, Ютазы авылы,
Дмитров урамы, 2
тел. 4-00-91
факс: 8 (85593) 4-00-93**

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**ЮТАЗИНСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**423962 с. Ютаза,
ул. Дмитрова, д.2
тел. 4-00-91
факс: 8 (85593) 4-00-93**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 3** **от «29» января 2021 г.**

2021 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы «Җирләү һәм җирләү эше турында»гы 8-ФЗ санлы Федераль закон, 2021 елның 28 гыйнварындагы Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2021 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында»гы 673 санлы карары, 2007 елның 18 маендагы "Җирләү һәм җирләү эше турында" «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында»гы Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 196 санлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге башкарма комитеты, к а р а р и т т е:

1. Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән әлеге карарның 1 санлы һәм 2 санлы кушымталары нигезендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясен 6424,98 сум (алты мең дүрт йөз егерме дүрт сум 98 тиен) күләмендә гамәлгә кертергә һәм билгеләргә

2. 2020 елның 17 июнендәге «Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елга Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең хакын раслау турында»гы 16 санлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ютазы авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча бастырырга http://pravo.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында «Татарстан Республикасы рәсми порталы» дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталын «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

4. Әлеге карар рәсми халыкка хәбәр ителгән көннән үз көченә керә.
5.Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге башлыгы Р.М.Галимов

2021 елның 29 гыйнварыннан
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге
башкарма комитетының
3 санлы карарына
1 кушымта

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
БӘЯСЕ

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 654,45 |
| 3. Үлгән кеше гәүдәсен (калдыкларын) зиратка кадәр алып бару | 754,12 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3 016,41 |
| **Барлыгы** | **6 424,98** |

2021 елның 29 гыйнварыннан
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлеге
башкарма комитетының
3 санлы карарына
2 кушымта

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Ютазы авыл җирлегендә 2021 елның 1 февраленнән
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге
БӘЯСЕ

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сумнарда) |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 045,71 |
| 3. Үлгән кеше гәүдәсен (калдыкларын) зиратка кадәр алып бару | 754,12 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 3 016,40 |
| 5. Гәүдәне кәфенгә төрү | 608,75 |
| **Барлыгы** | **6 424,98** |